**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» август, 2020 ел № 1057

2020 елның III кварталына салым
салынырга тиешле гражданнар
керемене һәм мөлкәт хакының
чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31 номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы һәм һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы нигезендә,

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2020 елның 29 июнендәге 351/пр номерлы «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2020 елның икенче яртыеллыгына бәясе нормативы һәм 2020 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынының гомуми

мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» боерыгына таянып, Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

2020 елның III кварталына гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы ставкасы:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 346 878,50 сум

1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 1 714 209 сум

1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 2 203 983 сум

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен - 2 938 644 сум

1.1.5. Биш кешелек гаилә өчен - 3 673 305 сум

1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 4 407 966 сум

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен - 5 142 627 сум

1.2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык керем күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 16 145,30 сум

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 10 274,28 сум

1.2.3. Өч кешелек гаилә өчен - 8 806,53 сум

2. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдалануны социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондын исәпкә кую һәм аларга торак урыннары бирү максатларында аз керемле дип тану өчен файдаланырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Район башкарма
комитеты җитәкчесе А. В. Хәбибуллин